РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КИЛЬДЮШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422387 с. Кильдюшево, ул. Молодёжная, 22

422387 Килдеш авылы, Яшьләр урамы, 22

тел. (84373) 5-22-66,e-mail: Kld.Tet@tatar.ru
ОГРН 1021606559325, ИНН/КПП 1638001590/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24.10. 2024** **№ 41-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" 2014 елның 10 ноябрендәге 51-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына таянып, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлеге Советы:

1.Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында " 10.11.2014 ел, №51-1 карарына өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләр (комплекслар) буенча 2025-2027 еллар күчеш чорына 1,2 процент, һәм алардагы биналар, 2028 елдан күрсәтелгән биналарда 2 процент ставкасы билгеләнә"

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә һәм «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Килдеш авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**Җитәкче** **В.С. Исаев**